Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының унберенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

10 июнь, 2021 ел № 81

Питрәч муниципаль районы территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы Советының 2007 елның 29 сентябрендәге 30 номерлы карары белән расланган Питрәч муниципаль районы территориясендә гражданнарның җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1.2 пунктының «һәм Питрәч муниципаль районы җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары,» сүзләреннән соң «инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре,» сүзләрен өстәргә;

1.2. «Гомуми нигезләмәләр» I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.12 пункт өстәргә:

«1.12. Инициатив проектлар кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә житкән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында инициатив проектларны күрсәтү, кертү, тикшерү һәм карау тәртибе Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов